**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5206**
**17.07.2025**

Рәсми чара үткәрү көнендә Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертү турында

Рәсми чара үткәрелү сәбәпле, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатында, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Законының 27 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Региональ яки муниципальара, җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яки вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы Карары, шәһәр Уставының 41 статьясындагы 9 өлешнең 24.1 пунктчасы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М

1. 2025 елның 22 июлендә 4.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр тугызынчы комплексның (Яңа шәһәр) квартал эчендәге юлы буенча ике юнәлештә дә Дружба Народов проспектына кадәр юл участогында, урап узу маршрутын 1 нче, 2 нче кушымталарда каралганча билгеләп, транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә.

2. Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенә транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында гражданнар иминлеген, җәмәгать тәртибен, юл хәрәкәтен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

3. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә:

1) әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә;

2) әлеге карарны, «Интернет» челтәрендә ведомствоның рәсми сайтында урнаштыру өчен, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына җибәрергә;

3) транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне һәм автомобиль юлларын ябу өчен кирәкле йөк транспорты бирүне тәэмин итәргә;


4) өстәмә мәгълүмат билгеләре белән тиешле юл билгеләрен урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 17 июлендәге
5206 номерлы карарына
1 нче кушымта


Юлларны ябу схемасы




Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2025 елның 17  июлендәге
5206 номерлы карарына
2 нче кушымта

Урап узу схемасы




Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева